# Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
# Башкарма комитеты
# карары

**№5996**
**13.11.2020**

Башкарма комитетның 2020 елның 7 апрелендәге 1728 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы боерыгы, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 7 апрелендәге 1728 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәнең 14 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктчада җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- гражданнар оборонасы курслары һәм гражданнар оборонасы буенча укыту-консультация пунктлары булдыру, җиһазландыру һәм аларның эшчәнлеген оештыру, шулай ук тиешле лицензиясе булган өстәмә һөнәри белем бирү учреждениеләрендә муниципаль берәмлекнең гражданнар оборонасы вазыйфаи затларының һәм хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүне тәэмин итү;»;

2) 3 пунктчада икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- халыкны, материаль һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычлар ихтималы булган зоналардан куркынычсыз районнарга эвакуацияләү буенча чараларны планлаштыру, әзерләү һәм үткәрүне оештыру, шулай ук сугыш вакытында үз эшчәнлеген дәвам итүче оешма хезмәткәрләрен һәм гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итүче оешма хезмәткәрләрен таратып урнаштыруны оештыру;»;

3) 4 пунктчада икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын һәм аларның техник системаларын саклау, билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту һәм техник хезмәт күрсәтү;»;

4) 6 пунктчада икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрү өчен кирәкле гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасын булдыру, җиһазландыру һәм әзерләү, шулай ук аларның гамәлләрен планлаштыру;»;

5) 7 пунктчада сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- куркынычсыз зонада кирәкле дәвалау базасы төзү, аны энергия һәм су белән тәэмин итүне оештыру;»;

6) 9 пунктчада икенче абзацны төшереп калдырырга;

7) 13 пунктчада:

- бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- мәетләрне эзләү, аларны табу урыннарын билгеләү, чыгару һәм һәлак булганнарны беренчел чистарту, һәлак булганнарны тану һәм документлаштыру, илтү һәм күмү буенча эшләрне оештыру;»;

- түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«санитар-эпидемиологик күзәтчелек оештыру.»;

8) 16 пунктчада дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- гражданнар оборонасы көчләренең гамәлләрен планлаштыру;».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов